ИСПОЛНИТЕЛЬНЫЙ КОМИТЕТ
МУСЛЮМОВСКОГО
МУНИЦИПАЛЬНОГО РАЙОНА
РЕСПУБЛИКИ ТАТАРСТАН

ТАТАРСТАН РЕСПУБЛИКАСЫ
МӨСЛИМ
МУНИЦИПАЛЬ РАЙОНЫ
БАШКАРМА КОМИТЕТЫ

**ПОСТАНОВЛЕНИЕ** **КАРАР**

31.01.2025 Мөслим ав. № 33

# Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясен раслау турында

«Россия Федерациясендә җирле үзидарә оештыруның гомуми принциплары турында» 2003 елның 06 октябрендәге 131-ФЗ номерлы Федераль закон, «Күмү һәм җирләү эше турында» 1996 елның 12 гыйнварындагы 8-ФЗ номерлы Федераль закон, Россия Федерациясе Хөкүмәтенең «2025 елда түләүләр, пособиеләр һәм компенсацияләр индексациясе күләмен раслау турында» 2025 елның 23 гыйнварындагы 33 номерлы карары белән, «Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы җирлекләренең җирле әһәмияттәге аерым мәсьәләләрне хәл итү вәкаләтләренең бер өлешен бирү турында» 2024 елның 29 маендагы 1904 номерлы Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Советы карары нигезендә, Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районы Башкарма комитеты **КАРАР БИРӘ:**

1. 2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләрнең бәясен әлеге карарга 1 нче кушымта, 2 нче кушымта һәм 3 нче кушымта нигезендә 9 165,37 сум күләмендә билгеләргә һәм гамәлгә кертергә.
2. Әлеге карарны Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районының рәсми сайтында һәм Татарстан Республикасы хокукый мәгълүматының рәсми порталында рәсми рәвештә халыкка җиткерергә http://pravo.tatarstan.ru.
3. Әлеге карар 2025 елның 1 февраленнән үз көченә керә.
4. Әлеге карарның үтәлешен контрольдә тотуны үз өстемдә калдырам.

**Башкарма комитет җитәкчесе** **И.Ф. Салихҗанов**

ТР Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
33 номерлы карарына 1 нче кушымта

# 2025 елның 1 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында, авыл җирлекләрен дә кертеп, җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге нигезендә күрсәтелә торган хезмәтләр бәясе

| № т/б | Муниципаль берәмлекнең, авыл җирлекләренең исеме | Җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе, сум. |
|---|---|---|
| 1 | «Әмәкәй авыл җирлеге» МБ | **9 165,37** |
| 2 | «Баланлы авыл җирлеге» МБ | |
| 3 | «Баек авыл җирлеге» МБ | |
| 4 | «Олы Чакмак авыл җирлеге» МБ | |
| 5 | «Варәшбаш авыл җирлеге» МБ | |
| 6 | «Исәнсеф авыл җирлеге» МБ | |
| 7 | «Крәш-Шуран авыл җирлеге» МБ | |
| 8 | «Мәллә-Тамак авыл җирлеге» МБ | |
| 9 | «Метрәй авыл җирлеге» МБ | |
| 10 | «Михайловка авыл җирлеге» МБ | |
| 11 | «Мөслим авыл җирлеге» МБ | |
| 12 | «Түбән Табын авыл җирлеге» МБ | |
| 13 | «Яңа Усы авыл җирлеге» МБ | |
| 14 | «Октябрь авыл җирлеге» МБ | |
| 15 | «Симәк авыл җирлеге» МБ | |
| 16 | «Иске Карамалы авыл җирлеге» МБ | |
| 17 | «Тойгелде авыл җирлеге» МБ | |
| 18 | «Үрәзмәт авыл җирлеге» МБ | |
| 19 | «Шуган авыл җирлеге» МБ | |

ТР Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
33 номерлы карарына 2 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасы Мөслим муниципаль районында җирләү буенча хезмәтләрнең гарантияләнгән исемлеге бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 3 913,97 |
| 3. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1 259,58 |
| 4. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 3 991,82 |
| **Барлыгы** | 9 165,37 |

ТР Мөслим муниципаль районы
Башкарма комитетының
2025 елның 31 гыйнварындагы
33 номерлы карарына 3 нче кушымта

2025 елның 01 февраленнән Татарстан Республикасының Мөслим муниципаль районында җирләү буенча гарантияләнгән хезмәтләр исемлегенең бәясе

| Хезмәтнең исеме | Хезмәт күрсәтү бәясе (сум) |
|---|---|
| 1.Җирләү өчен кирәкле документларны рәсмиләштерү | 0,0 |
| 2.Тәнне кәфенләү | 164,78 |
| 3.Табутны һәм җирләү өчен кирәкле башка предметларны бирү һәм китереп бирү | 3 749,19 |
| 4. Мәрхүмнең мәетен (җәсәден) зиратка алып бару | 1 259,58 |
| 5. Җирләү (каберләр казу һәм күмү) | 3 991,82 |
| **Барлыгы** | 9 165,37 |